## ТУГАН ЙОРТКА

Айрат Нәбиев көе
(Дамира Сәитова репертуарыннан)

Авылыма кайтсам, капкам бикле.
Нигеземә үскән кычыткан.
Моңсу йозак моңсу караш белән
Көтә микән мине бик күптән?!

*Кушымта:*
Кайда әткәм? Кайда әнкәм?!
Кайда минем туганнар?!
Кайда гармун? Кайда җыр-моң?!
Дуслар кайда булганнар?!
Туган йортның тәрәзләрен
Ник кадаклап куйганнар?!

Газиз туган авылым урамында
Йөгереп йөри чит-ят балалар,
Йорт башында яткан агач тайлар
Йөрәккә ник шом-зар салалар?

*Кушымта.*

Авылыма кайтсам, капкам бикле,
Ишегемдә тутык зур йозак.
Чирәмнәргә ятып еласам да,
Кайтмас яшьлек, кайтмас балачак.

*Кушымта.*